**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Кукеевского**
**сельского поселения**
**Рыбно Слободского**
**муниципального района**

**Новая ул., дом 5,**
**с.Кукеево, 422669**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Куки**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

**Яна урамы, 5 нче йорт,**
**Куки авылы , 422669**

**Тел.: (84361) 30581 факс: (84361)30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2022 Күки авылы №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 24 нче ноябрендэ 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, уку йортларына йөреп укучы студентлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Су белән тәэмин итү системаларын , су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын ремонтлау:
- Урам яктырту җайланмаларын төзекләндерү .
- Торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.
- Кышкы һәм җәйге чорда Күки авылы эчендәге юлларны тәртиптә тоту өчен;

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Күки авылы, Яңа урамы, 5

йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов